РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

18 октябрь 2019 ел                                   № 33

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законга таянып, 09.10.2019 ел Туйкә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссия бәяләмәсе нигезендә, карар чыгарам:

1. Туйкә авыл җирлеге Советының 19.02.2014 ел №72(31.10.2014 № 97, 09.03.2016 № 28-10, 29.11.2016 №47-23, 11.09.2017 № 68-32, 16.07.2018 № 104-49; 19.03.2019г. № 132-63 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын әзерләүгә керешергә.

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- мәйданы 18501,0 кв. м. булган, 16:02:060303:375, 16:02:060303:376 кадастр номерлы, ТР, Азнакай муниципаль районы, Туйкә авыл җирлеге адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны С12 махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасыннан һәм авыл хуҗалыгы җирләре (СХУ) җирләреннән авыл хуҗалыгы (СХ1) билгеләнешендәге объектлар зонасына үзгәртергә;

- мәйданы 4784,0 кв.м. булган, 16:02:060301:223 кадастр номерлы,ТР, Азнакай муниципаль районы, Туйкә авылы, Ленин урамы, 22 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны Ж1 шәхси торак төзелеше зонасыннан СХ1авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасына үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару

Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча эш тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.//. Веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калыдрам.

Башлык Закирова Р.Р.

Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл
җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына кушымта 1
№ 33  18 октябрь 2019 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү буенча эшләр башкаруның якынча вакыты**

| N | «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча эшләрне үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2019 ел IV квартал |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зонасы картасына үзгәрешләр кертү, җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2019 ел IV квартал |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Халык тыңлаулары үткәрү.<br>Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Башлыгына җир биләмәләреннән файдалану Кагыйдәләренә һәм аңа карата мәҗбүри кушымталар (ачык тыңлаулар протоколы һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) кертү турында карар кабул итү өчен, Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында проектын авыл җирлеге Советына раслауга яки кире кагу һәм аны кабат эшләп бетерү өчен җибәрү турында карар кабул итү өчен җибәрергә. | 2019 ел IV квартал |